Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 13 16.12.2020 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне кабул итү хакында» 2019 ел, 18 февраль, 95 нче карарына (2020 ел, 2 февраль, 124 номерлы карарның үзгәрешләре белән) үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 ел, 2 март, 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2020 ел, 8 июнь, 181-ФЗ номерлы, 2020 ел, 31 июль, 268-ФЗ номерлы, 2020 ел, 27 октябрь, 347-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 ел,25 июнь, 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Илтерәк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илтерәк авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне кабул итү хакында» 2019 ел, 18 февраль, 95 нче Карарына 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- 20 бүлекнең 3 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»

- 20 бүлекнең 3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»

- 34 бүлегендәге 4 пунктка сүзләр өстәргә:
«булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру»

- 15 пунктның 3 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәр урынбасары булган муниципаль хезмәткәр, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфа биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар»

2. Иске Илтерәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә һәм Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Аксубай муниципаль районы
Иске Илтерәк авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе С.М. Маклаков